# КАРАР
## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Язлы Арташ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

31.10.2025 №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Арташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арташ авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2025 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыенында «2026 нче елда Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Язлы Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Язлы Арташ торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегендә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _38_е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Язлы Арташ торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2026 нче елда Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Язлы Арташ торак пунктында Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Язлы Арташ торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Язлы Арташ торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге караны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында: https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арташ авыл җирлеге башлыгы Р.И.Мөхәрләмов